МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.04.2024 Казан ш № 264

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 29 декабрендәге 971 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 29 декабрендәге 971 номерлы боерыгы ( Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 27 июнендәге 627 номерлы, 2022 елның 7 ноябрендәге 989 номерлы, 2023 елның 5 сентябрендәге 720 номерлы, 2024 елның 9 гыйнварындагы 1 номерлы боерыклары керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2024 елның 16 апрелендәге 264 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 29 декабрендәге 971 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.3.1 пунктының өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сөйләшүләр алып барылуы турында хәбәр итү яисә Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкның мәшгульлегенә булышлык итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле документларның рәвешләрен раслау турында» 2024 елның 30 гыйнварындагы 32н номерлы боерыгы (алга таба - 2024 елның 30 гыйнварындагы 32н номерлы боерык) белән расланган үрнәк буенча эшкә юллау;»;

2.4.8 пунктта «20.10.2021 №738н» сүзләрен «30.01.2024 №32н» сүзләре белән алмаштырырга;

2.6.1 пунктның икенче абзацында «20.10.2021 №738н» сүзләрен «30.01.2024 №32н» сүзләре белән алмаштырырга;

2.6.2 пунктында бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән эшсезлек буенча пособие билгеләү өчен эш бирүче тарафыннан уртача хезмәт хакы исәпләнгән очракларда, теркәлгән гражданин шәхсән үзе Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча эш бирүче тарафыннан исәпләнгән уртача хезмәт хакы турында белешмә тапшыра.»;

2.6.5 пунктында:

алтынчы абзацта «соңгы эш (хезмәт) урыны буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

җиденче абзацта «Инвалидларның федераль реестры» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» сүзләре белән алмаштырырга;

унდүртенче һәм унбишенче абзацлары үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«мәҗбүри пенсия иминияте системасында формалаштырылган пенсия хокуклары турында мәгълүмат – Россия Федерациясенең Пенсия һәм социаль

иминият фонды;»;

2.8.5 пунктта:

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) гражданинны «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» федераль законның 3 статьясы нигезендә мәшгуль дип тану;»;

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) теркәлгән гражданинның төзәтү яки мәҗбүри эшләргә хөкем ителүе, шулай ук, әгәр мондый җәза шартлы рәвештә билгеләнмәгән булса, иректән мәхрүм итү рәвешендә җәзага тартылуы;»;

«г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) теркәлгән гражданинның «Россиядә эш» порталын яки Бердәм порталны (гаризаны Бердәм портал аша җибәргәндә) яки Татарстан Республикасы порталын (гаризаны Татарстан Республикасы порталы аша җибәргәндә) кулланып, гариза теркәлгән мөрәҗәгать итүче тарафыннан кире алынган очракта, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге күрсәтә торган тиешле эш эзләү ярдәменнән баш тартуы. Теркәлгән гражданин тарафыннан гаризаны кире алу, үзен эшсез дип тану өлешендә гражданин тарафыннан гаризага үзгәрешләр кертелгән очракта, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан гаризага һәм резюмега гариза халыкның мәшгульлек үзәгендә кабул ителгән көнгә кадәр үзгәрешләр кертелгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан күрсәтелә торган ярдәмнән баш тарту булып тормый;»;

3 бүлектә:

3.3.4.4 пунктының өченче абзацында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уртача хезмәт хакын исәпләү турында» 2023 елның 24 июнендәге 1026 номерлы карары белән расланган тәртиптә саналган соңгы эш (хезмәт) урыны буенча уртача хезмәт хакы турында» сүзләрен «Россия Федерациясенең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган тәртиптә саналган уртача хезмәт хакы турында» сүзләре белән алмаштырырга;

3.4.1 пунктта:

җиденче абзацта «соңгы эш (хезмәт) урыны буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

сигезенче абзацта «Инвалидларның федераль реестры» сүзләрен «Социаль өлкәдә үзәкләштерелгән бердәм цифрлы платформа» сүзләре белән алмаштырырга;

унбишенче һәм уналтынчы абзацларны үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«мәҗбүри пенсия иминияте системасында формалаштырылган пенсия хокуклары турында мәгълүмат – Россия Федерациясенең Пенсия һәм социаль иминият фонды;

3.5.2 пунктының бишенче абзацында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 24 июнендәге 1026 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләр нигезендә исәпләп чыгарылган соңгы эш (хезмәт) урыны буенча уртача хезмәт хакы турында» сүзләрен «Россия Федерациясенең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы

тарафыннан расланган тәртиптә саналган уртача хезмәт хакы турында» сүзләре белән алмаштырырга;

3.5.3 пунктның тугызынчы һәм уналтынчы абзацларында «соңгы эш урыны буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.5.6 пунктның өченче абзацында «20.10.2021 №738н» сүзләрен «30.01.2024 №32н» сүзләре белән алмаштырырга;

3.5.9 пунктның егерме икенче абзацында «20.10.2021 №738н» сүзләрен «30.01.2024 №32н» сүзләре белән алмаштырырга;

3.6.5 пунктының унынчы һәм унберенче абзацларында «20.10.2021 №738н» сүзләрен «30.01.2024 №32н» сүзләре белән алмаштырырга;

Административ регламентка 4 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнарга туры килә торган эш
эзләүдә булышлык күрсәтү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
4 нче кушымта

Форма

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль
яклау министрлыгының 2024 елның 30
гыйнварындагы 32н номерлы боерыгы
белән расланды

Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза

1. Мөрәҗәгатьнең максаты (мәгънәсен сайларга)

☐ Мин эш эзлим һәм эшсез дип танылуга дәгъва белдермим

☐ Мин эш эзлим һәм эшсез дип танылуга дәгъва белдерәм

2. Фамилиясе, исеме, атасының исеме
(булган очракта)[1] ____________________________

3. Туган көне [1] ____________________

4. Яше [1] ______________ (тулы еллар)
5. Җенесе [1] __________________

6. Гражданлыгы [1] ____________________________

7. Шәхесне раслаучы документ турында мәгълүмат [1]:

---

[1] Автомат рәвештә тутырыла.

________________________________________
документның исеме
серия ___________ номеры ______________ бирү датасы « ____ « ___________ 20 ____ ел.
кем тарафыннан бирелгән ____________________________________________________________

8. ИНН [1] _________________________

9. СНИЛС [1] ___________________________

10. Адрес (мәгънәсен сайларга)[2]:

☐ яшәү урыны буенча теркәлү

☐ тору урыны буенча теркәлү

10.1 Россия Федерациясе субъекты _______________________________________________________

10.2 район, торак пункт _____________________________________________________________

10.3 урам ______________________________________________________________________________

10.4 йорт, корпус, бина _____________________________

10.5 фатир __________________________

11. Элемтәгә керү өчен белешмәләр:
11.1 телефон _________________________________________________

11.2 электрон почта адресы ________________________________

12. Дәүләт хезмәтен алу урыны:
12.1 Россия Федерациясе субъекты _______________________________________________________

12.2 халыкны эш белән тәэмин итү үзәге _________________________________________________________

13. Эш эзләү өчен Россия Федерациясенең кирәкле субъектлары: _______________

___________________________________________________________________________________________

14. Социаль дәрәҗә:
14.1 эшсез дип танылуга дәгъва итүче гражданин өчен (мәгънәләрне сайларга):

☐ пенсия алды яшендәге пенсионер [3]

☐ инвалид

☐ ятим бала, ата-ана каравыннан мәхрүм калган бала, ятим балалар, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар исәбендәге бала

---

[2] Эшсез дип танылуга дәгъва итмәгән гражданин өчен яшәү урыны буенча теркәлү адресы яки яшәү урыны буенча теркәлү адресы күрсәтелә (сайлап); эшсез дип танылуга дәгъва итүче гражданин өчен яшәү урыны буенча теркәлү адресы күрсәтелә.

[3] Картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирүче яшькә җиткәнче 5 ел дәвамында гражданин, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнә торган (Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-I номерлы законының 5 статьясы).

☐ 18 яшькә кадәрге баланың (балаларның) ата-анасы (уллыкка алучысы), аның тууы факты Россия Федерациясендә теркәлгән

☐ 18 яшькә кадәрге баланың (балаларның) опекуны, аның тууы факты Россия Федерациясендә теркәлгән

☐ 18 яшькә кадәрге баланың (балаларның) ата-анасы (уллыкка алучысы), аның тууы факты чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан теркәлгән

☐ төрмә җәзасын үтәүче учреждениедән азат ителгән, һәм азат ителгәннән бирле бер елдан артык булмаган чорда эш эзлим

☐ качак/мәҗбүри күченүче

☐ хәрби хезмәттән җибәрелгән

☐ хәрби хезмәттән җибәрелгән гражданинның гаилә әгъзасы

☐ ялгыз/күпбалалы ата-ана (опекун, попечитель), тәрбияләүче балигъ булмаган балалар, инвалид балалар

☐ Чернобыль радиациясенә дучар булган гражданин/башка радиация авариясе яки һәлакәткә очраган зат

☐ 18 яшьтән 25 яшькә кадәрге, уртача һөнәри белемле гражданин яки югары белеме булган һәм белем һәм квалификация турында документ бирелгән көннән ашлап бер ел эчендә эш эзләүче зат

☐ югарыда санап үтелгәннәрнең берсе дә түгел

14.2 эшсез дип танылуга дәгъва итмәгән гражданин өчен (мәгънәләрне сайларга):

☐ мин эшлим, ләкин эшне үзгәртергә/өстәмә эш табарга телим

☐ көндезге уку формасы буенча укыйм

☐ пенсия алды яшендәге пенсионер [3]

☐ инвалид

☐ ятим бала, ата-ана каравыннан мәхрүм калган бала, ятим балалар, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар исәбендәге бала

☐ 18 яшькә кадәрге баланың (балаларның) ата-анасы (уллыкка алучысы), аның тууы факты Россия Федерациясендә теркәлгән

☐ 18 яшькә кадәрге баланың (балаларның) опекуны, аның тууы факты Россия Федерациясендә теркәлгән

☐ 18 яшькә кадәрге баланың (балаларның) ата-анасы (уллыкка алучысы), аның тууы факты чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан теркәлгән

☐ пенсионер

☐ 3 яшькә кадәр бала карау ялында

☐ 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган зат

☐ төрмә җәзасын үтәүче учреждениеләрдән азат ителдем һәм азат ителгәннән бирле бер елдан артык булмаган чорда эш эзлим

☐ качак/мәҗбүри күченүче

☐ хәрби хезмәттән җибәрелгән

☐ хәрби хезмәттән җибәрелгән гражданинның гаилә әгъзасы

☐ ялгыз/күпбалалы ата-ана (опекун, попечитель), тәрбияләүче балигъ булмаган балалар, инвалид балалар

☐ Чернобыль радиациясенә дучар булган гражданин/башка радиация авариясе яки һәлакәткә очраган зат

☐ 18 яшьтән 25 яшькә кадәрге, уртача һөнәри белемле гражданин яки югары белеме булган һәм белем һәм квалификация турында документ бирелгән көннән ашлап бер ел эчендә эш эзләүче зат

☐ югарыда санап үтелгәннәрнең берсе дә түгел

15. Эшсез дип танылa алмаган граждaннар категориясенә керү (гариза бирелгән көнгә статусы күрсәтелә)[4, 5]:

15.1 16 яшенә җитмәгән балигъ булмаган бала:

☐ әйе ☐ юк

15.2 картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән пенсионер (шул исәптән вакытыннан алда)/мәшгульлек хезмәте органы тәкъдиме буенча пенсия/картлык буенча пенсия яки дәүләт пенсия тәэминаты буенча күпьеллык хезмәте өчен:

☐ әйе ☐ юк

15.3 суд карары буенча төзәтү яки мәҗбүри эшләргә хөкем ителгән/ ирегеннән мәхрүм итү рәвешендә шартлы рәвештә билгеләнмәгән җәзага тартылган:

☐ әйе ☐ юк

15.4 хезмәт килешүе буенча эшлим/дәүләт яки муниципаль хезмәт үтим/башка түләүле эшем (хезмәтем) бар[6]:

☐ әйе ☐ юк

15.5 шәхси практика белән шөгыльләнүче шәхси эшкуар/нотариус/адвокат/федераль законнарга ярашлы рәвештә һөнәри эшчәнлеге дәүләт теркәвенә алынырга һәм (яки) лицензияләнергә тиешле башка зат буларак теркәлгән зат:

☐ әйе ☐ юк

15.6 шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару белән мәшгуль/традицион хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыру/кәсепләр белән шөгыльләнәм (халык сәнгать кәсепләре, Россия Федерациясенең аз санлы җирле халыкларының традицион кәсепләре) һәм килешүләр буенча продукция сату белән шөгыльләнәм:

☐ әйе ☐ юк

[4] Эшсез дип танылуга дәгъва итүче граждaннар гына тутыра.
[5] Һәр пункт буенча «әйе» яки «юк» вариантын сайларга кирәк.
[6] Сайлау комиссиясе, референдум комиссиясе әгъзасы вәкаләтләрен даими (штат) нигездә түгел, хәл итүче тавыш хокукы белән гамәлгә ашыручы гражданин "юк" вариантын билгели.

15.7 гражданлык-хокукый характердагы килешү (килешүләр) буенча эш башкарам, аның предметы булып эшләрне башкару һәм (яки) хезмәтләр күрсәтү тора/авторлык заказы килешүе (килешүләре) буенча эш башкарам:

☐ әйе ☐ юк

15.8 түләүле вазыйфага сайланган (билгеләнгән) яки түләүле вазыйфага расланган:

☐ әйе ☐ юк

15.9 хәрби хезмәткә чакыру буенча/альтернатив гражданлык хезмәте буенча/»Оборона турында» 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы федераль закон белән каралган ирекле формированиедә булам:

☐ әйе ☐ юк

15.10 вакытлыча эшкә яраксызлык/отпуск/һөнәри белем алу, һөнәри белем алу яки өстәмә һөнәри белем алу/хәрби җыеннарга чакырылу/хәрби хезмәткә әзерлек (альтернатив гражданлык хезмәте) белән бәйле чараларга җәлеп итү аркасында производствоны туктату/башка дәүләт яки җәмәгать бурычларын үтәү/башка хөрмәтле сәбәпләр аркасында вакытлыча эш урынымда түгелмен:

☐ әйе ☐ юк

15.11 корпоратив коммерция оешмасында катнашам (әгъзасы булып торам):

☐ әйе ☐ юк

15.12 мин крестьян (фермер) хуҗалыгы әгъзасы:

☐ әйе ☐ юк

15.13 белем бирү эшчәнлеген алып баручы оешмада көндезге уку формасы буенча укыйм:

☐ әйе ☐ юк

15.14 эшләми торган эшкә сәләтле кеше, I төркем инвалидны/инвалид баланы/медицина бәяләмәсе нигезендә даими чит кеше каравына мохтаҗ булган яки 80 яшькә җиткән өлкән кешене карыйм:

☐ әйе ☐ юк

15.15 мин тәрбиягә бала алган ата-ана/өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар өчен тәрбиягә бала алган гаилә булдырдым:

☐ әйе ☐ юк

15.16 һөнәри керемгә салым түләүче:

☐ әйе ☐ юк

16. Эшсезлек буенча пособие алу ысулы (мәгънәне сайларга)[7]:

☐ банк счетына ______________________________
алучы банкының исеме

«Мир» илкүләм түләү системасы картасы номеры ______________________

алучы банкының БИК ______________ Алучы банкының ИНН ______________

алучының счеты ____________ алучы банкының корреспондент счеты ____________

☐ әлеге адрес буенча почта аша күчерү: ______________________________

17. Мәгълүматны раслау:

[7] 15 пунктның 15.1 - 15.16 пунктчаларының һәркайсында "юк" варианты билгеләнгән очракта гына тутырылырга мөмкин.

☐ Миңа кисәтү ясалды: әгәр бирелгән мәгълүматлар ялган булса,
мине Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартырга (җәлеп итәргә) мөмкиннәр.

☐ Мин шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә риза
әлеге мөрәҗәгать һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча.

☐ Мин шәхси мәгълүматларны өченче затларга халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү максатында тапшыруга риза

☐ Эш һәм хезмәт хакы булмау турында алдан ук ялган белешмәләр һәм (яисә) эшсез дип тану өчен кирәкле башка дөрес булмаган белешмәләр биргән очракта, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан миңа эшсез сыйфатында теркәү исәбенә куелу кире кагылачак, мине эшсез дип тану турындагы мәсьәләне хәл итү өчен кабат мөрәҗәгать итү кире кагылган көннән бер ай узгач кына мөмкин булачак, бу хакта миңа кисәтү ясадылар[8].

☐ Миңа кисәтү ясадылар, әгәр мәшгульлек хезмәте органының туры килә торган эш
эзләүдә ярдәменнән баш тартуга бәйле рәвештә теркәлү исәбеннән алынсам, мине эшсез дип тану турындагы мәсьәләне хәл итү өчен кабат мөрәҗәгать итү кире кагылган көннән бер ай узгач мөмкин булачак.

☐ Миңа кисәтү ясадылар, эшсезлек буенча пособие ялган юл белән алган очракта,
(шул исәптән дөрес булмаган белешмәләр биргәндә) халыкның мәшгульлек үзәге законсыз рәвештә алынган акчаларны суд тәртибендә түләтергә хокуклы, ә тиешле материаллар хокук саклау органнарына тапшырылачак [8.]

☐ Халыкны эш белән тәэмин итү турындагы закон нигезләмәләре белән танышуым турында
раслыйм.

[8] Эшсез дип танылуга дәгъва итүче гражданнар гына тутыра.